ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Федераль телерадиотапшырулар конкурсы комиссиясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле турында

Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 2012 елның 25 маендагы 522 номерлы боерыгы белән расланган Федераль телерадиотапшырулар конкурсы комиссиясе турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Федераль телерадиотапшырулар конкурсы комиссиясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле итеп Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Зарипов Айрат Ринат улын билгеләп куярга.
2. «Телерадиотапшырулар буенча федераль конкурс комиссиясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле турында» 2019 елның 25 сентябрендәге 83-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 20 сентябре
№ 34-VII ДС